**Яшел Үзән шәһәренең**
**5нче гимназиядә**
**Иң өлгер һәм акыллы**
**Сабиров Карим мин.**



▪Әбиемнең күңел сандыгы!
Нинди серләр саклый икән ул?
Гомер буе җыйган хәзинәме,
Әллә инде күңел бизәгеме?
Нинди серләр саклый икән ул?



Әбиебез сандыгында
Сакланмый ниләр генә.
Әйдәгез сорыйк үзеннән,
Ачып күрсәтсен безгә.

Бу минем дәү әнием –
Салисә Камилевна.



Сөртенсәң – сөлге кирәк,
Көрәшсәң – сөлге кирәк.
Батырларга сабантуйда
Бирелгән сөлге – бүләк!



**Бизәк төшкән итекләрне**
**Читекләр дип йөрткәннәр.**
**Аларны татар кызлары**
**Бәйрәмнәрдә кигәннәр.**



Яулыклар күп төрле алар,

Читләре бизәкләнгән.

Нур сибелә, нур чәчелә,

Нур бөркелә алардан.







Ай, ак калфагым!
Җепкә тезгән
энҗе ак инәдә.
Энҗе калфак –
милли хәзинә лә!

Балкып тора түбәтәйләр
Энҗе бөртекләр белән.
Алар монда килгән гүя
Чын әкият иленнән.



## **Түбәтәй - төрки халыкларда ирләрнең төп баш киеме**



Борын-борыннан ирләр өйдә түбәтәй кияргә яратканнар.

Түбәтәй чигә һәм тегә белгән кеше алтын куллы оста санала.



Кара бәрхеткә ука яисә сәйлән белән чигелгән түбәтәйләрне бәйрәмдәрдә генә кияләр. Ә көндә кияр өчен сырып тегелгән, кара бәрхет түбәтәйләр була.

Кәләпүшем, кәләпүш,
Энҗе-мәрҗәннәр чиккән!
Чиккән кәләпүш үземә
Бигрәк килешә икән!
Кәләпүшем, кәләпүш,
Бизәгендә бар ае.
Киеп куйсаң сокланалар
Мин бит татар малае.



Бу байлыкны урнаштырып,
Әби сандыгын япсын.
Безнең кебек балаларга
Тагын ачып күрсәтсен.





Буыннар чылбырын саклап калганда гына милләтебезнең киләчәге матур һәм ышанычлы булачак.

